САЙЛАУДАН СОҢ

Апас һәм Биектау районнарында яңа җитәкчеләр билгеләнде

> 2

СОҢГЫ МОГИКАН

Татар җәмәгатьчелеге милләтпәрвәр сәясәтче Фәндәс Сафиуллинны соңгы юлга озатты

> 3



ЧИРМЕШӘН ТАШКАЗАННАРЫ

Кармыш авылы янәшәсендәге табигать һәйкәленең сере нидә?

> 4

ӨЧ КИЯҮ БЕЛӘН ТОРМЫШ

Тинчурин театры яңа сезонның беренче премьерасын тәкъдим итте

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 148 (28730) | Сишәмбе | 12 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

КОД ЭЧЕНДӘГЕ ИРЕК

Яңа атнаны кодлардан башладык. Коронавируска бәйле вазгыять киеренке, шуңа да республика хакимияте күпләр өчен яңалык булган әлеге адымга барырга мәҗбүр булды. Вазгыятьне уңай якка боруның башка чарасын белмибез, диләр. Яңалык үзе артыннан күп сораулар да алып килде. Вакцина кадатмаган булсаң, нишләргә? QR-кодны кайдан һәм ничек табарга? Шул хакта аңлатабыз.

Автор фотосы

«Бүтән юл юк»

Чикләү чараларының ни сәбәпле катгыйлануын «шимбә киңәшмәсе»ндә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та аңлатты. Шунысы төгәл билгеле: кагыйдәләр үтәлешен таләп итәчәкләр һәм тикшерәчәкләр.

– Статистикага карасаң, үлүчеләр арту күзәтелә. Кызганыч, өлкәннәр генә түгел, яшьләр дә китә. Кабул иткән карарларны һәркем төрлечә аңлый. Кемнәрдер уңай карый, башка юл юк икәнен чамалый. Аңлыйбыз, халыкның бер өлеше битлектән дә, чикләүләрдән дә туйгандыр. Әмма, кызганыч, бүтән юлыбыз юк, – диде республика җитәкчесе. – Кабул ителгән чикләүләрнең үтәлешен катгый таләп итәчәкбез.

Оныткан булсагыз, сүз нинди чикләүләр турында барганын искә төшереп үтәбез.

- Театр, кинотеатр, цирк, концерт залларында, спорт, мәдәният, күңел ачу чараларында халык саны 50 проценттан артмаска яисә 500 кешедән дә күбрәк булмаска тиеш. Аерым таләпләр үтәлгән очракта гына тамаша залын 70 процентка тутырырга рөхсәт ителә. Бу шартларга барлык хезмәткәрләрнең һәм оештыручыларның вакцина ясатуы, коронавирус белән чирләве хакында яисә вакцина ясатырга ярамавы турында белешмәләрнең берсен күрсәтүе кирә. Оештыручылар чараны үткәрү турында бер атна алдан Татарстанның оператив штабы белән килештерергә тиеш. Спорт, күңел ачу, мәдәни чаралар турында исә 30 көн алдан кисәтергә кирәк булачак.
- Кунакханәләр 50 процентка гына тулы булырга тиеш. Анда да хезмәткәрләрнең барысы да вакцина ясаткан, тиешле документларның булуы шарт. Бу шартлар үтәлсә, кунакханәләр тулы куәткә эшли ала.
- 400 кв. м мәйданнан артып киткән җәмәгать туклану урыннары, спорт, фитнес, сәүдә-күңел ачу үзәкләре, аквапарк, бассейн, азык-төлек белән сәүдә итмәгән кибетләргә QR-код күрсәткән очракта гына йөрергә рөхсәт ителә.
- Прививкасы булмаган һәм соңгы ярты елда коронавирус белән авырмаган 65 яшьтән өлкәнрәк кешеләр өчен мәҗбүри үзизоляция режимы гамәлгә керә. Ашыгыч медицина ярдәме, коронавируска каршы прививка кадату, кибеткә, чүп түгү урынына бару, йорт хайванын 100 метр ераклыкта булмаган арада йөртү кебек сәбәпләр белән өйдән чыгарга ярый. Эш бирүчеләр исә мондый хезмәткәрләрнең читтән торып эшләү мөмкинлеген кайгыртырга тиеш.

Күпләр «медотвод» бар дип, җиңел сулап куярга мөмкин. Әмма ул җәмәгать урыннарына йөрү хокукын бирми. Бары тик QR-код кына санап үткән урыннарга тоткарлыксыз керү ысулы булып тора.

18 яше тулмаганнар турында аерым әйтеп үтик. Яңа чикләү чаралары аларга кагылмый. Ягъни бу категориягә караган кешеләр җәмәгать урыннарында мөстәкыйль рәвештә яисә QR-коды булган ата-анасы белән бергә йөри ала. Бу очракта үзең белән йә паспорт, йә туу турында таныклык йөртү мәҗбүри.

QR-код: куллану инструкциясе

QR-код белән моңа кадәр дә очрашканы бар инде халыкның. Мәсәлән, кибеттә товар алганда. Башкача әйтсәк, берәр объект турында мәгълүматны үз эченә алган штрихкод бу. Димәк, хәзерге вазгыятьтә кулланыла торганы кешенең вакциналы-мы-юкмы, коронавирус кичергәнме-юкмы икәне турында мәгълүмат бирә.

Хәрәкәтләнү иреге бирә торган кодны кайдан табарга соң? QR-код «Дәүләт хезмәтләре» порталындагы шәхси кабинетта саклана. Вакцинация турындагы QR-код прививканың икенче дозасын алганнан соң барлыкка киләчәк. Бу кодны «Госуслуги Стоп Коронавирус» мобиль кушымтасы ярдәмендә яки «Дәүләт хезмәтләре» порталыннан алырга (телефон экранына чыгарып күрсәтәсе. – **Ред.**) яисә кәгазьгә бастырырга мөмкин.

Ахыры 2 нче биттә >

Соңгы мәгълүматлар буенча, Татарстанда коронавируска каршы вакцинаны барлыгы 1121845 кеше ясаткан. Бер тәүлектә 14100 кеше прививка кадаткан. Вакцинаның икенче дозасын 968484 кеше алган.

Иң суык сентябрь

Быелгы сентябрь илнең Европа өлешендә соңгы 25 елда иң салкын ай булып истә калачак. Биредә айлык уртача һава температурасы нормадан түбәнрәк булган. Кайбер төбәкләрдә салкын һава буенча яңа рекордлар теркәлгән. Аномаль эссе җәйгә алмашка беренче көннәреннән үк суык көз килгәч, шулай булмый хәле юк… Моннан тыш Россиянең күпчелек өлешендә айлык явым-төшем күләме нормадан артып киткән.

Татарстанда көзнең беренче ае яңгырлы һәм суык булды. Республиканың Гидрометеоүзәге хәбәр иткәнчә, узган айда тәүлеклек уртача һава температурасы +9,8 градус тәшкил иткән. Ниһаять, бу атнада чын мәгънәсендә әбиләр чуагы килә – көндезге температура +17 градуска җитәчәк. Кичә көндез Татарстанда +14 градус җылы булды. Кайбер районнарда яңгырлар яуды. Бүген көндез +11… +16 градуска кадәр җылыта. Төнлә +2 +7 градус җылы, явым-төшем көтелми. Чәршәмбе һәм пәнҗешәмбедә исә көндез +17 градуска кадәр җылытачак. Төнлә температураның 0… +7 градус булуы көтелә. Җомга һәм шимбә көннәрендә кайбер районнарда бераз гына явым-төшем булырга мөмкин. Төнлә температура +2… +7, көндез +10… +15, шимбә көнне +8… +13 градус тәшкил итәчәк.

Волонтерлар җанисәп алуда катнаша

Казанда җанисәп алуга 2,7 меңнән артыграк кеше җәлеп ителәчәк. Болар – җанисәп алучылар, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре һәм контролерлар. Бу хакта Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илдар Шакиров белдерде. Аның әйтүенчә, халык санын алу беренче тапкыр волонтерлар ярдәмендә үткәреләчәк. Алар халыкка җанисәп алу турында сөйләячәк, киңәш бирәчәк. Казанда 116 кеше волонтер сыйфатында җанисәп алуда катнашуга гариза тапшырган инде.

Илдар Шакиров сүзләренә караганда, җанисәп алганда мәгълүматлар сер булып калачак. Аларда кешеләрнең адреслары, исем-фамилияләре һәм башка мәгълүматлар күрсәтелмәячәк. Башлангыч нәтиҗәләрне 2022 елның IV кварталында бастырып чыгару күздә тотыла. «Ил күләмендәге төп чара бу. Безнең җавапларга күп нәрсә бәйле», – ди Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Фаҗига

Соңгы сикерү

ТАТАРСТАНДА ОЧКЫЧ ҺӘЛАКӘТКӘ ОЧРАП, 16 КЕШЕНЕҢ ГОМЕРЕ ӨЗЕЛДЕ

Татарстанда – фаҗига. Ял көне бар халыкны тетрәндергән авиаһәлакәт 16 кешенең гомерен өзде. Республикада матәм көне игълан ителде.

Фаҗига турында иртәнге 9лар тирәсендә билгеле булды. Минзәлә районында самолет һәлакәткә очрады. L-410 очкычында 22 кеше булган: 14 парашют белән сикерүче, алты инструктор һәм ике очучы. Очкычта төрле төбәктән килгән кешеләр булган. Башкортстаннан килгән 6 кешенең дүртесе һәлак булган, икесе исән. Мари Иленнән 1 кеше, ул да исән. Удмуртиядән 3 кеше, икесе һәлак, берсе исән. Татарстаннан барлыгы 9 кеше, барысының да гомере өзелгән, Кировтан 1 кеше – исән, Чиләбедән килгән 1 спортчы һәлак булган.

Шул ук көнне фаҗига булган урынга килгән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов самолетның бер двигателе эшләми башлау аркасында һәлакәткә очравын хәбәр итте. Аның сүзләренчә, очучылар элемтә югалганчы бу хакта хәбәр итәргә өлгергән.

– 70 метр биеклектә очучылар сул як двигательнең эшләми башлавын хәбәр итә һәм мәҗбүри төшеп утыруны сорый. Күреп торабыз, очыш озак дәвам итмәгән. Алар сулгарак киткән, чөнки алда торак пунктлар тора. Ләкин тиешле биеклекне ала алмаганнар. Хәзер без торган урында «ГАЗель» автомобиле торган һәм самолет аны канаты белән эләктергән. Нәтиҗәдә очкыч әйләнеп капланган, – диде ул.

Шулай ук район башлыгы Айдар Сәлахов сүзләренчә, якынча версияләр арасында двигательгә кош эләгүе дә бар. Болардан тыш, һәлакәткә җиңел моторлы самолетның йөге артык күп булуы да китерергә мөмкин, дип фаразлана. Татарстан ДОСААФ Үзәк Аэроклубның Минзәлә филиалы җитәкчесе Равил Нурмөхәммәтов исә очучыларының дөрес эш итүләрен һәм фаҗигане булдырмый калу өчен мөмкин булганны эшләүләрен белдерде. Аның фаразлавынча, 1987 елда җитештерелгән очкычның двигателенә кош эләккән булырга мөмкин. Тәҗрибәле очучылар очкычны торак йортлардан читкәрәк алып китәргә тырышкан дип фаразлана.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Ахыры 3 нче биттә >

Татармын! Горурмын!



Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ, Татарстанның халык язучысы:

Милли хисең турында кычкырып йөрмә, эчеңдә тот. Аны эштә күрсәт һәм гомереңбуе йөрәгеңдә сакла, күңелеңдә үстер, җаныңда тот. Күп сөйләшми генә зур эшләр башкар, әмма әйткәнеңне һәрвакыт: «Мин әйттем!» – диң. Безнең бабайлар – бөек ханнар – шулай дигәннәр. Үзеңне һәрчак татар морзасы яисә ханы итеп той. Онытма: һәр татар үз эшендә хан булырга яратылган! Татар булуың белән мактанма. Әмма горурлан!

(«Татарның милли кыңгыравы» җыентыгыннан)

РОССИЯНЕҢ ИҢ БАЙ ТӨБӘКЛӘРЕ

«РИА Новости» агентлыгы халыкның матди хәле буенча Россия төбәкләре исемлеген төзегән. Исемлекне әзерләгәндә халыкның керем күләме һәм башка икътисади күрсәткечләр исәпкә алынган.

1. Ямал-Ненец автономияле округы
2. Магадан өлкәсе
3. Чукотка автономияле округы

…

13. Свердловск өлкәсе
14. Татарстан

…

84. Тыва
85. Ингушетия

Интернет саклык сорый

Соңгы ике елда Россиядә киберҗинаятьләр саны 1,5 тапкыр арткан. Моны коронавирус пандемиясе белән дә бәйлиләр. Бу хакта эчке эшләр министры Владимир Колокольцев белдергән. Аның әйтүенчә, пандемия җәмгыятьнең «цифрлашуын» көчәйткән: өйдә торып уку һәм эшләүгә күчү сәбәпле, кешеләр интернеттан күбрәк файдалана башлаган. Моннан тыш оешмалар да электрон хезмәт күрсәтүгә өстенлек бирә. Боларның барысы да IT-җинаятьләрнең үсүенә китергән. Колокольцев әйтүенчә, мондый җинаятьләрнең төп өлеше мошенниклыкка туры килә.

КамАЗ тизлеген арттыра

КамАЗ автомобильләр җитештерүне 21 процентка арттырган. Компания агымдагы елның тугыз аенда 31 меңләп машина эшләп чыгарган инде. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу күрсәткеч 21 процентка артыграк, дип хәбәр итә компаниянең матбугат хезмәте.

Сентябрь аенда автомобиль заводы 4067 машина җитештергән. Узган елның шушы аенда исә 3676 автомобиль конвейердан төшкән булган.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

УТ БЕТҮ

Үткән атнада глобаль икътисадның тектоник плитәләре үзара ныграк бәрелешеп тетрәнүне көчәйтте. Яңалык тасмалары «Дөньяны азык-төлек инфляциясе шогы чолгап алды. Ашауга бәяләр күтәрелеше соңгы ярты елдагы рекорд куйды» дигән башисем астында чыга. Әммә бу – бәланең кечкенә бер өлеше генә. Энергетик кризис бар куәтенә яшәешкә китерел суга. Европада хәтта, энергиягә бәяләр күтәрелү сәбәпле, бәдрәф кәгазе җитештерү туктатылды дигән хәбәрләр килә. Без беләбез бит инде: зур кризисның беренче карлыгачы ул – кәгазь кытлыгы.

Энергетик кризисның флагманы булып исә Якын Көнчыгыштагы кечкенә генә дәүләт – Ливан килә. Шимбә көнне анда масштаблы ут өзелү башланды. Илдә иң зур ике электр станциясе, ягулык бетү сәбәпле, эшен туктатты. Төньяктагы Дейр-Аммардагы һәм көньяктагы Захран ТЭСлары, Берләшкән Гәрәп Әмирлекләреннән мазут килеп җитмәү сәбәпле, караңгылыкка чумды һәм шуның аркасында бөтен ил утсыз калды. Ливан Хөкүмәте ягулык сатып алу өчен ашыгыч рәвештә акча бүлеп бирде, әммә дә ләкин мазут килеп җиткәнче, ике атна вакыт кирәк булыр, диләр. Хәрбиләрнең стратегик ягулык запасларын тота башлап, дүшәмбедән генераторларны эшкә җигеп булмасмы дигән өмет тә бар. Моның кысыр өмет булуы да мөмкин. Эш бит мазутның юклыгында түгел, түлә генә, илне нефть продуктлары белән тутырачаклар. Мәсьәлә акча юклык белән катлауланa. Җәйдән үк Ливан утны иркенләп тота алмады. 2–4 сәгать кенә электр бирелә иде. 12 августта илнең Үзәк Банкы, валюта резервлары бетү сәбәпле, ягулык-майлау материалларын субсидияләүне туктатты. Бу ягулык салу станцияләрендә бензин бетүгә һәм масштаблы протестларга китерде. Август аенда гына да мотор ягулыгына бәяләр 66 процентка күтәрелгән иде. 22 сентябрьдә хөкүмәт бәяләрне тагын 15 процентка арттырды.

Күрше гарәп илләре, Ливанга кайсы электр энергиясе, кайсы газ һәм ягулык-майлау материаллары озатып, киеренкелекне йомшартырга тырыша. Тик андый ярдәм бушай була алмый. Булса да бик кечкенә генә булышу килеп чыга. Финанс кытлыгы бәяләр күтәрелү фонында барлык илләрнең дә үкчәсенә басып килә бит.

Вазгыять фәкыйрь илләрдә генә түгел, бай Көнбатышта да катлаулы. Германиянең иң зур электр энергиясе сатучы Rheinische Elektrizitäts-und Gasversorgungsgesellschaft компаниясе үзенең йөзләгән клиентына электр сатуны туктатуы турында белдерде. Сәбәбе – чималга бәяләрнең кискә сикерүе. Компания сентябрьдә беренче тапкыр тарифларны күтәреп карады. Ул энергияне җитештерми, ә күмәртәләп сатучылардан ала. Тегеләре исә күпләп сату бәясен гел өскә этәләр. Котировкалар артыннан куып җитә алмагач, энергияне ваклап бүлүче әлеге компания 19 октябрьдән электр озатуны туктату турында карар кабул итте.

Германиядә ел башыннан электр бәясе 3 тапкыр үскән инде. Спот базарында үсеш исә – 1000 процент. Белгечләр илдә газ запасы «шок тудыра торган түбән» дип бәяләде. Ташкүмер бәяләре дә югарыга омтылган. Җил станцияләре энергия җитештерүне 30–40 процентка киметкән, чөнки Европада штиль – талгын җил генә исә. Кызык заманнар җитте.

Россиядә

ХАЛЫК КИТӘ, ҖИРНЕ АРЕНДАГА БИРӘБЕЗ

Россиягә әлегә ут бетү янамый. Куркыныч башка яктан китереп кабыргага төртә: ил халкы кискен темплар белән кырыла. Демографик упкын турында без беренче тапкыр гына язмыйбыз, әммә Росстатның яңа игълан иткән саннарына игътибар итми калып булмый.

Үлем-китемнәр саны кискен темплар белән үсә, туучылар саны бик нык кими. Җомга көнне Росстат быелның гыйнвар – август айларында 1 миллион 523 мең кешенең якты дөнья белән бәхилләшүен хәбәр итте. Кешеләр узган ел да күп үлгән иде, тик быел үлүчеләр саны 18,5 процентка үскән. Кеше исәбенә күчергәч, 238 мең дигән сан чыга. Үткән елның сентябреннән быелның августын кертеп (12 айда) вафат булучылар 2 миллион 360 меңгә җиткән. Мондый тискәре рекорд советтан соңгы чорда 2003 елда куелган булган. Тормыш бик авыр булган, чор белән чор кисешкән 1990 елларда да кешеләр алай ук күп үлмәгән. Ә бит рекордлы инфляция һәм масскакүләм эшсезлек дәвере булган ул елларда бик күпләр өметсезлеккә бирелгән иде. Ул унъеллыкта үлем рекорды 1994 елда куелган: бер елда 2 миллион 300 мең кеше дөньяны калдырган. Мең кешегә 15,7 үлем очрагы туры килә хәзер. Бу – соңгы 15 елның иң югары коэффициенты. Быелның август аенда гына да 208,4 мең үлем теркәлгән. Бу 2020 ел августыннан өчтән бергә күбрәк. Вице-премьер Татьяна Голикова әйтүенчә, үлем очраклары артуның 81,7 проценты COVID-19 белән бәйле.

Росстат августтагы 49,3 мең үлемне коронавирус белән бәйли. Шуларның 43,5 меңенең төп сәбәбе – COVID-19. Бу язгы көнди белән бәйле үлемнәрдән ике тапкыр артыграк.

Туучылар саны 1 процентка кимегән. 12 айда 1 миллион 426 мең бала туган. Бу – 2002 елдан соң минимум. Нәтиҗәдә халык саны алдагы ел белән чагыштырганда 1,7 тапкыр зуррак тизлек белән кимегән. Россияле гаиләләр бала табарга теләми. Бары тик бер россияле хатын гына, төрек бизнесмены белән гаилә корып, 100 бала тудырып үстерергә планлаштыра. Хатынга – 24, иргә – 55 яшь. 24 яшьлек Кристинаның инде 22 баласы бар. Дөрес, ул аларны үзе тапмаган, суррогат әниләрне эшкә җиккәннәр. Менә шул ысул белән балалар санын йөзгә тутырырга ниятлиләр икән. Болай эшләргә ярамый, әлбәттә. Гадәти ысул белән һәр гаилә 3–4 бала табып үстерсә дә, демография төене чишелер иде.

Халык бигрәк тә авылларда кими бит инде. Нәтиҗәдә сөрелмәгән җирләр миллионлаган гектарлап арта. Аптырагач, федераль хөкүмәт 1 миллион гектар җирне Үзбәкстанга арендага бирергә булган. Үзбәкләр ашлыкны монда үстереп, үз илләренә ташырга телиләр. Мәскәүнең ниятен губернаторлар да күтәреп алган. Алар аренда җирен миллион гектарлар да арттырырга вәгъдә итәләр. Рус милләтпәрвәрләре бу уйлардан социаль челтәрләрдә тавыш кубарды. Ярты Кырым җире кадәр җир китә, дип аһ итәләр. Әммә авылга кайтып чәчәргә-урырга теләүчеләр күренми.

БАШЛЫКЛАР АЛЫШЫНА: КЕМ УРЫНЫНА КЕМ КИЛДЕ?

Татарстанда район башлыклары алышыну дәвам итә. Шимбә көнне Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Апас һәм Биектау районнары советының чираттан тыш утырышларында катнашты.

Апас районын әлегә кадәр Равил Хисаметдинов җитәкләгән иде. Ул әлеге вазыйфасыннан китеп, Биектау белән идарә итә башлады. Фәрит Мөхәммәтшин аңа эшләгән эшләре өчен рәхмәт әйтте һәм кайбер күрсәткечләр буенча районның лидерлар рәтендә торуын билгеләп узды. Район башлыгы кәнәфиенә исә Айрат Җиһаншин утырды. Моңа кадәр ул «Сетевая компания» филиалы – «Буа электр челтәрләре» җәмгыяте директоры булып эшләде. Апас районының яңа башлыгы тумышы белән шушы районнан. Казан дәүләт энергетика университетын һәм Россия Президенты каршындагы Россия дәүләт хезмәте академиясен тәмамлаган. Аның хезмәт эшчәнлегенең күпчелек өлеше «Буа электр челтәрләре» компаниясе белән бәйле. Айрат Җиһаншинны электромонтердан филиал директорына кадәр күтәрелгән кеше буларак беләләр.

Фәрит Мөхәммәтшин яңа җитәкчегә уңышлар теләде. Айрат Җиһаншинны исә хезмәттәшләре идарәче, энергияле, ветераннар һәм яшьләр арасында авторитет казанган кеше дип бияли.

Чираттагы утырыш Биектау районында дәвам итте. Районның элеккеге башлыгы Рөстәм Кәлимуллин үзенең Дәүләт Думасына китүен, ләкин кайда гына эшләсә дә, күңеле белән биектаулы булып калуын әйтте.

– Алга таба да бергә эшләрбез, – дип мөрәҗәгать итте ул залда утыручыларга.

Фәрит Мөхәммәтшин Биектау районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын башкаручы итеп билгеләнгән Равил Хисаметдиновка уңышлар теләде.

– Ул да – Рөстәм Галиуллович кебек әзерлекле, берничә районда эшләп, зур мәктәп узган кеше. Һәр районда булган яхшы эшләр һәм традицияләр сакланыр дип ышанам, – дип өмет баглады парламент башлыгы.

Равил Хисаметдинов тумышы белән Буа районыннан. 2002–2005 елларда Буа районы һәм Буа шәһәре администрациясе оешудыру бүлегенең мобилизация һәм махсус эш буенча бүлек белгече булып эшли. 2005 елда «Ак Барс Мед» иминият компаниясе» җәмгыяте филиалы директоры була. Шулай ук 2005 елда Буа районы һәм Буа шәһәре хакимиятендә хакимият аппараты җитәкчесе булып эшли. 2006 елдан Буа район Советы Аппараты җитәкчесе, 2008 елдан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары итеп билгеләнелә. 2013 елда Менделеевск районы башкарма комитеты җитәкчесе була. 2014–2017 елларда – Апас Башкарма комитеты җитәкчесе. 2017 елдан 2019 елга кадәр – Татарстан Баш инвестиция-төзелеш идарәсе җитәкчесе урынбасары. Апас районы белән 2019 елдан бирле җитәкчелек иткән иде.

Исегезгә төшерәбез: узган атнада Түбән Кама районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы итеп Рамил Муллин билгеләнде. Моңа кадәр әлеге район белән җитәкчелек иткән Айдар Метшин шулай ук Дәүләт Думасына китте. Мөслим районы башлыгы урынына исә 47 яшьлек эшмәкәр Альберт Хуҗин килде.

Чыгышлары белән Татарстаннан булган якташларыбыз башка өлкәләрдә дә уңышка ирешә. Теләче районында туган, 2006–2011 елларда шул районның Башкарма комитетын җитәкләгән Алмаз Хәкимов Пенза өлкәсенең икътисади үсеш һәм сәнәгать министры вазыйфаларын башкаручы итеп билгеләнде.

Зәһрә САДЫЙКОВА

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстанда «Урманны саклыйк» бөтенроссия акциясе кысасында 20 меңнән артык волонтер 300 гектардан артык мәйданда барлыгы 1,2 млн үсенте утыртты. Казанда Республика балалар клиник хастаханәсе территориясендә пандемия чорында фидакарь хезмәт куйган табиблар хөрмәтенә 300 чыршы һәм нарат утыртылды. Чарада Президент Рөстәм Миңнеханов, Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева, урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров, сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков, Яшьләр хөкүмәте рәисе Алла Абросимова катнашты. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, республикада урман хуҗалыгын үстерүгә җитди игътибар бирелә. Урман фондын арттыру эшен профильле министрлык алып бара, ә мондый акцияләр катнашучыларга урманга сак караш тәрбияләргә мөмкинлек бирә.

***

Казанда гадәттән тыш эпидемиологик хәлләр килеп туганда мобиль лабораторияләр ярдәмендә тиз генә чаралар күрергә тиешле халыкара командалар өйрәнүләре ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. «Казан Экспо» территориясендә узучы чарага шулай ук Роспотребнадзор оешмасы җитәкчесе – Россия Баш санитар табибы Анна Попова килде.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бүген – дөньяда коронавирус инфекциясенә каршы көрәш дәвам иткән бер мәлдә өйрәнүләр үткәрүнең аеруча мөһимлеген искәртте. Ул республиканың эпидемиологик иминлекне игътибар үзәгенә алуны таләп иткән зур халыкара чаралар оештыру буенча зур тәҗрибәгә ия булуын билгеләп үтте. Мобиль лабораторияләр барлык зур чараларда биологик иминлекне тәэмин итуда катнашты, диде Рөстәм Миңнеханов.

Халыкара өйрәнүләрдә ерак һәм якын чит илләрнең – Бельгия, Германия, Франция, Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Үзбәкстан командалары катнаша.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

Татарстан Республикасында 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан итү турында

Цифрлы икътисадның алгарышлы үсеше өчен уңай шартлар тудыру, Татарстан Республикасы халкының тормыш сыйфатын яхшырта торган цифрлы технологияләрне, сервисларны һәм хезмәт күрсәтүләрне нәтиҗәле үстерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Цифрлаштыру елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2021 ел, 08 октябрь
№ ПУ-800

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты **Лаврентьев** Александр Петрович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

КОД ӘЧЕНДӘГЕ ИРЕК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Күптән түгел коронавирус кичергән кешеләрнең белешмәсе дә шунда саклана. Искәртеп үтик: барыбер «Дәүләт хезмәтләре» порталында шәхси кабинет булдырырга туры киләчәк, чөнки җәмәгать урыннарында тоткарлыксыз йөрү өчен нәкъ тә электрон теркәлү сорала. Бу җәһәттән һәр кешегә өлкән туганнарын порталда теркәү, кодка бәйле сорауларны хәл итү өчен ярдәм итәргә киңәш ителә. Заманча гаджетка ия булмаганнар мәсьәләсен ничек хәл итәргә икәнен хәзер Роспотребнадзор өйрәнә.

Коронавирус белән симптомнарсыз гына чирләгән, регистрда теркәлмәгәнсез икән, кодлы булу бәхете тәтемәячәк. Коронавируска каршы антитәнчекләр да тыелган урыннарга йөрү мөмкинлеген бирми. ПЦР-тест тапшырган очракта, QR-код нибары өч тәүлек – 72 сәгать кенә эшли. Аннан янә ясатасы. Бу исә – чыгымлы хезмәт.

Иска төшерүнең зыяны булмас: вакцина ясату турындагы белешмәне «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша гына алырга мөмкин. **Башка ысул юк!** Кемдер эшләп бирәм, шәхси кабинетыгызга урнаштырам дисә, ышанмаска киңәш итәбез. Кырыгалдарлар кулына калуыгыз ихтимал.

QR-код алу белән мәшәкатьләр туган очракта, 122 «кайнар элемтә» номерына шалтыратырга яисә вакцина ясаткан медицина оешмасына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

QR-кодсызларга кая да булса йөрергә рөхсәт ителәме соң? Яңа чикләүләр сәүдә үзәкләрендә булмаган азык-төлек кибетләренә, сәүдә залы мәйданы 400 кв. метрдан артмаган сату нокталарына, банк, даруханә, почта, мунча, чәчтарашханә һәм җәмәгать транспортына кагылмый. Димәк, коды булмаган кешеләр шушы урыннарда тоткарлыксыз йөри ала.

Шунысы да истән чыкмасын: кафе-рестораннарга һәм сәүдә үзәкләренә коронавируска каршы вакцинаның бер компонентын ясаткан килеш әләгү мөмкин түгел!

Чикләү булган җирдә аны читләтеп үтәргә җыенучылар да табылыр. Ялган белешмәләр, кодлар сатып алып, акчасыз каласың, закон алдында җавап бирәсен дә онытмасак иде.

Аннан, QR-коды булу әле битлек киюдән һәм коронавирус өйрәткән кагыйдәләрне үтәүдән азат итми. Шулай ук штрафтан да.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА



Илдар Мөхәммәтҗанов

Могҗиза көтәсе түгел

Татарстанда коронавируска каршы мәҗбүри вакцина ясату режимы гамәлгә кертелде. Тиешле карарны республиканың баш санитар табибы Марина Патяшина имзалады.

Шулай итеп 60 яшьтән өлкәнрәкләр, медицина, белем бирү, социаль тармак учреждениеләре, транспорт һәм энергетика өлкәсе, сәнәгать һәм төзелеш предприятиеләре, авыл хуҗалыгы оешмалары хезмәткәрләре, хокук саклау органнары вәкилләре, хәрбиләр, волонтерлар, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, вахта ысулы белән эшләүче затлар мәҗбүри рәвештә коронавируска каршы вакцина ясатырга тиеш.

Әлеге таләп чәчтарашханә, мунча, спорт учреждениеләре, көнкүреш хезмәтләре, сәүдә һәм җәмәгать туклануы нокталары, почта, кәрәзле элемтә салоннары, торак-коммуналь хуҗалык оешмалары, кино, музей, концерт, күргәзмә заллары, китапханә, ял үзәкләре, балалар лагерьлары, туризм өлкәсе, массакүләм мәгълүмат чаралары, даруханә, ветеринария клиникалары, кунакханәләр, автосервисларда эшләүчеләргә дә кагыла.

Уку йортыннан читтә практика узарга җыенган студентлар да прививка кадатырга тиеш була.

Оешма җитәкчеләре бу елның 6 декабренә кадәр хезмәткәрләрнең прививканың ике компонентын да кадатуларын тәэмин итәргә мәҗбүр. Вакцинациянең беренче этабын да узмаган хезмәткәрләр 9 ноябрьдән эштән җибәрелергә тиеш. 7 декабрьдән исә коронавируска каршы прививканың икенче этабын узмаучылар эштән азат ителәчәк.

Хезмәт коллективларында вакцина ясатучылар күрсәткече 80 процент булырга тиеш. Шунысы бар: әгәр кайсыбер хезмәткәрләр дистанцион рәвештә эшләвен дәвам итә һәм алар эш урынына йөрми икән, аларны вакцинация узарга тиешле хезмәткәрләр исәбенә кертмәскә була. Әгәр дә алар хезмәт урынына кайтырга карар кыла икән, бу кешеләр вакцина ясатырга тиеш.

Могҗиза көтәр чак түгел. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Марина Патяшина әлеге чикләү чараларының нәтиҗәләре булырмы дигән сорауга:

– Республикада вирус инфекцияләренең күтәрелеш чоры. Шуңа да могҗизалар көтәсе түгел. Вакцина ясатуның да нәтиҗәсе беренче мизгелдә үк булмаячак. Иммунитет барлыкка килсен өчен 40–50 көн вакыт кирәк. Чикләүләр аркасында кеше күпләп йөри торган урыннарга килүчеләр кими, бу да чир таралу тизлегенә йогынты ясаячак, – диде.

QR-кодлы тормышның ни кадәр озакка сузыласын фаразлау кыен. Марина Патяшина әйтүенчә, мондый яңалык кертүнең төп бурычы – вакцина ясатучыларның санын арттыру.

Вакцина барысына да җитәчәк, дип ышандыралар. «594354 доза вакцина бар. 1,1 миллион кешегә прививка кададык, 2,4 миллион булырга тиеш. Шуңа да кирәкле күләмдә вакцина белән тәэмин итү белән мәшәкать булмаячак. Карарда күрсәтелгән гражданнар категориясе өчен вакцина җитәрлек», – диде Марина Патяшина.

Идарә башлыгыннан QR-кодларның чынлыкка туры килү-килмәвен ничек итепраслап буласын сораштылар. Аның сүзләренчә, исбатлау өчен паспорт яисә машина йөртү таныклыгы кирәк. QR-кодсыз, вакцина турындагы гадәти белешмә белән генә ирекле хәрәкәтләнү мөмкин түгел. Марина Патяшина кабат кисәтте: электрон код ялган белешмәләр пәйда булуына киртә куя.

Коронавирустан прививка мәҗбүри булган кешеләрнең аны ясату өчен ике ай вакыты бар. Шуңа күрә бу вакыттан дөрес итеп файдаланып калырга өндиләр.

СӘЯСӘТТӘ ТУКАЙ ИДЕ

ТАТАР ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕ КҮРЕНЕКЛЕ СӘЯСӘТЧЕ ФӘНДӘС САФИУЛЛИН БЕЛӘН ХУШЛАШТЫ

Бу көзләрдә асыл затларыбыз китә. Соңгы могикан, сәясәттә Тукаебыз, көрәшчебез Фәндәс Сафиуллин да бакыйлыкка күчте. Суверенлык өчен көрәштә алгы сафларда булган көрәшче, Дәүләт Советында Декларацияне иң беренче укучы, Милли мәгариф дип җан атучы, Чечня сугышына яшь солдатларны җибәрмәскә дигән карар кабул итүгә ирешүче... Саный китсәң, ул башкарган игелекләрне санап бетергесез...

«Мин китәрмен, халык кала бит»

Китте, хәзер инде кадерен белмәдек, дип терсәкне тешлибез. Җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев әнә шул фикердә:

– Ул безнең, бер караганда, иң кадерле кешеләребезнең берсе, чынбарлыкта исә без аның кадерен белеп бетермәдек. Аның соңгы юбилее, 85 яшьлеге 17 августта булды, шул вакытта ул, шалтыраткан кеше дә, хәлне белгән кеше дә юк, дип әйтеп куйды. Билгеле, ул беркайчан да кычкырып үпкә-рәнҗешен белдерә торган кеше булмады, зарланырга яратмый иде. Ә бит иң кадерле зат булырга тиешле шәхес, ник дигәндә, татар халкы, республика өчен кылган гамәлләре искиткеч зур. Әгәр, туксанынчы еллардан яңа тарихыбыз башланып китте һәм шуннан соң бик зур уңай үзгәрешләр булды, дип әйтәбез икән, монда һичшиксез Фәндәс абыйның роле зур. Чөнки ул тарих Декларация кабул итүдән башланды. Фәндәс абый исә әлеге документны кабул иткәндә иң актив депутатларның берсе булды. Гомумән, ул вакытта ике кеше актив булды – Минтимер Шәймиев һәм депутат Фәндәс Сафиуллин. Референдум үткәргәндә дә, Конституцияне кабул иткәндә дә зур эшләр башкарды. Ул Конституция комиссиясе әгъзасы иде һәм тәкъдимнәрен дәлилләп үз фикерен үткәрә белде. Аның асыл сыйфаты да шунда: ул ышандыра белә иде. Ни өчен ышандыра, чөнки дәлилле сөйли. Законнарны, тарихны, әдәбиятны бик яхшы белә. Бу өлкәләрдән, дөнья тәҗрибәсеннән мисаллар китерә-китерә сөйли һәм үз артыннан башкаларны ияртә. Чөнки ораторлык осталыгы югары дәрәҗәдә. Ул искиткеч әзерлекле депутат иде. Туфан ага Миңнуллин бу хакта: «Безнең парламентта профессиональ депутат берәү генә, ул да булса Фәндәс Сафиуллин. Калганнарыбыз аның укучылары, өйрәнчекләр, үзешчәннәр», – дип әйткән иде. Ул чынлап та шулай. Егерменче гасырның башында Садри Максудилар булса, безнең заманда шул ук дәрәҗәдә үзенең фикерен җиткерә, сүзен әйтә алган, гамәлләр кылган депутат – Фәндәс Сафиуллин. Ул сәясәттә Тукай иде.

Без аның белән 24 сентябрьдә, Милләт җыеныннан соң бик озаклап сөйләшеп утырдык. Аның юбилеен да, кылган гамәлләрен дә искә алдык. Шунда ул: «Разил, мин үз язмышым өчен борчылмыйм, яшисен яшәдем, кулдан килгәнен эшләдем. Мине иң борчыганы – милләтебез, туган телебез, милли мәгариф, милли мәктәбебез язмышы. Мин китәрмен, халык кала бит. Аларның язмышы ничек булыр», – диде. Бу аның миңа әйткән иң соңгы сүзләре булды.

Аның асыл холкын ача торган бер мисал. Берзаманны Россия Дәүләт Думасында рус халкы турында закон проекты эшләнде. Ул проектта рус халкының нинди бөек булуы, мәнфәгатьләре, хокуклары турында бик тәфсилләп язылган иде. Әгәр ул кабул ителсә, башка халыклар икенче, өченче генә түгел, белмим, ничәнче сортлы булып калган булырлар иде икән?.. Шуннан соң без берничә фикердәш җыелыштык та татар халкы турында да шундый ук закон проекты эшләргә булдык. Рус халкы турындагы законны өлге итеп алдык та аның «Татар халкы турында»гы Законга әвереелдердек. Фәндәс абый аны Россия Дәүләт Думасы каравына кертте. Башка республикаларга да шундый ук закон эшләгез дип мөрәҗәгать иттек. Андый хәрәкәт тә башланды. Бер төрле законнар булгач, алар бергә каралырга тиеш иде. Нәтиҗәдә рус халкы турындагы закон автомат рәвештә төшеп калды. Гомер буе Фәндәс абыйның үҗәтлегенә шаккаттым. Әгәр ул бер эшкә алына икән, аны һичшиксез азагына кадәр җиткерә. Әйтик, алтмыштан узгач, ярты ел эчендә аккордеонда уйнарга өйрәнде. Үзенә максат куя икән, ул аны башкарып чыга иде.

«Кабатланмас шәхес иде»

Галим Индус Таһиров аны бәйсезлек өчен җанын фида кылган шәхес дип атады:

– Кабатланмас шәхес иде. Андыйлар элек тә юк дәрәҗәсендә иде, хәзер бөтенләй дә юк. Курыкмас, кыю, республика суверенитетын саклап калу өчен җанын фида кылган кеше… Югары Совет депутаты буларак, туксанынчы елдан башлап, соңыннан Дәүләт Думасы депутаты буларак та шушы изге эшне дәвам итте. Ул – Татарстанның суверенлыгына зур өлеш керткән кешеләрнең берсе. Ул Декларация кабул ителгән вакытта үзенең нинди асыл кеше булуын күрсәтә алды. Аның чыгышлары һәрберсе тарихи вакыйга булып язылып калды. Һич икеләнүсез әйтә алам: Фәндәс үзенең эшен уңышлы дәвам итүе аркасында Татарстан суверен республикага әверелде. Декларацияне кабул иткән вакытта иң актив кешеләрнең берсе булды, кабул ителгәч, Дәүләт Советы сессиясендә чыгып укыды. Мәскәү белән сөйләшүләр вакытында да актив катнашты, нәтиҗәдә тиешле шартнамәне төзи алдык. Шартнамә – халыкара, дәүләтара документ, ул анда ике дәүләт үзара вәкаләтләр бүлешү мәсьәләсендә бик зур эш эшләде.

«Исән чакта кадерен белмибез»

Язучы, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла, Фәндәс абыйның эше дәвам итәр әле дип өметләнә:

– Бу арада югалтулар бик күп булды. Киләчәктә тагын күпме булыр, бер Алла белә. Яхшы кешеләрне ала тора бит, нишләтәсең… 85 яшь аз гомер түгел, ләкин иртәрәк китте. Ул – көрәшче кеше, хәрби, төгәл кеше. Сүзен үлчәп сөйли торган, мантыйклы кеше иде. Аны «иде» дип сөйләү дә авыр… Азатлык өчен көрәш вакытында, сессиядә, шовинистларга җавап бирү мәсьәләсендә шулкадәр төгәл, ачык фикерле кеше иде. Шуңа күрә аны яратып та бетермәделәр. Аның үзенә каршы оештырылган эшләргә артык исе китмәде, мөмкин булганча эшләвен дәвам итте. Дискриминацион сәясәткә каршы алгы сафларда булды. Мин аның эше дәвам итәр дип уйлыйм.

Уйлап карасаң, безнең беркайчан да кеше кадерләгәнебез юк. Тукай юкка гына «мескен үлеп аңлатмагач» дип язып калдырмаган бит инде. Кеше киткәч, ядкәрләр язабыз, кадерен белмәдек, дип аһ итәбез, үзебез һаман исәннәрнең кадерен белмибез. Илһамның (Шакиров. – **Ред.**) кадере булдымы инде, Әлфия Авзалованы кадерләделәрме? Һәрвакыт өстән кыйнап, өсләреннән әләкләп тордылар. Икесе дә 60 ел җырлаган кеше буларак Гиннесснең рекордлар китабына кертергә лаеклылар иде, документ әзерләүче булмады, СССРның халык артисты исеме дә бирелмәде. Фәндәс тә шулар өммәтеннән. Алар мактау өчен, исем өчен эшләмәделәр. Кайберәүләр исем артыннан йөгереп йөри, арткы ишектән дә керәләр, аларга исем кирәк. Фәндәс кебек баһадирлар эш дип янды. Өлкәннәрдән курыкмаска кирәк. Киңәш, тәҗрибә алып калырга кирәк. Мин уйлыйм, Фәндәс абыйның эше дәвам итәр, аның тәэсирендә акыллы, булдыклы сәясәтчеләр тәрбияләнер. Йодрык болгау гына көрәш түгел әле ул, дипломатия, хәйлә, белем, дәрт, мөрәвәтле җан булырга кирәк.

«Милли университет соңгы әманәте булды»

Татарстанның халык артисты Гөлзада Сафиуллина соңгы тапкыр очрашу мизгелен, аның әйткән сүзләрен искә алды:

– 22 сентябрьдә Бөтендөнья татар конгрессында Аксакаллар шурасының җыены булды. Менә шунда Фәндәс абый белән янәшәдә утырдык. Ул шунда милли университет турындагы фикерен әйтеп калдырды. «Университет ул – безнең хыял. Әгәр аны тормышка ашырмасак, безнең киләчәгебез юк», – диде ул. Шушы очрашу соңгысы булыр дип кем уйлаган?! Икенче көнне мин бик каты авырып киттем, Милләт җыенында катнаша алмадым, Фәндәс абый анда катнашкан икән әле. Хәзер уйлыйм, ул вакытта авыргандыр инде ул, егетлеге белән, дәрт белән йөргәндер. Фәндәс абый гади кеше иде, бервакытта да үзен югары куймады, теләсә нинди темага иркенләп сөйләшеп була иде. Бу – бик зур югалту…

> **Фәрит МӨХӘММӘТШИН, Дәүләт Советы Рәисе:**
> – Татарстанда парламентчылыкны үстерүдә үзеннән зур өлеш керткән күренекле җәмәгать эшлеклесе-сәясәтче арабыздан мәңгегә китте. Фәндәс Шакир улы гасырлар чигендә парламентыбызның иң актив депутатларыннан берсе булды. Татарстанның дәүләтчелеген ныгытуга бәйле барлык чаралар аның катнашында узды. Ул үз халкының һәм республиканың мәнфәгатьләрен, дәлилләрен тирәнтен нигезләп, бик нык һәм оста итеп яклады. Дәүләт Думасы депутаты булганда, Мәскәүдә очрашкан чакларда, аннан үзебезне борчыган мәсьәләләр буенча чыгыш ясавын сорый идем, ул һәрвакыт безнең фикер-карашыбызны федераль парламентка түкми-чәчми җиткерә килде. Ул сөйли, аңлата белде, аны тыңладылар һәм аңладылар.

«Фикере ачык, сүзе дөрес, принциплары нык иде»

Соңгы айлар тоташ югалтулардан тора сыман. Алар арасында Фәндәс абыйны югалту бигрәк тә үкенечле. Милләт җыенының беренчесендә дә урынының балконда булып, кирәксезгә калуын белдергән иде инде ул. Бусында да… Акыллылардан курка торган халыкмы икән әллә без? Бу сүзләрне хушлашу мәрасименнән соң язмаска иде дә бит. Исән чакта фикерләрен тыңларга иде… Журналист Зимфира Гыйльметдинова кичергән хис бүген барыбыз өчен дә уртактыр ул:

– Хәзер табигатьнең алтын чоры, шулай да, барыбер моңсу бу көз. Хәвефле хәбәрләр күп, тынгысызлык, курку, гасабилану. Фәндәс абыйның вафаты хәбәре бар… Соңгы дистәдән артык елда аны очратканда, нигәдер карашны гел җиргә төби идем. Аның дәрәҗәсендәге сәясәтче, фикер иясенең гап-гади пенсионер булып калуында, әйтерсең, мин гаепле.

Мәскәүдән депутат мандатын тапшырып әйләнеп кайткач булса кирәк, ниндидер бер зур бәйрәмдә Фәндәс абыйны «протокол» зонасына уздырмаганнар. Аның белән бергә булган Туфан абый исемлектән Фәндәс Сафиуллин исемен тапмаган «каравылчы»ларны акылга китерә алмагач, «Алай булгач, мин дә кермим», – дип борылып киткән. Моны Туфан абый сөйләгәннән беләм. Шул сөйләшүдән соң башланды да кебек минем Фәндәс абый алдында уңайсызлануым.

Бернигә дә карамый, рухы сынмады кебек аның. Беркайчан, беркайда зарын ишеткән булмады. Әллә нинди «батырлар» интернетта аноним язып ятканда, ул фикерен һәрчак үз исеменнән язды. Фикере ачык, сүзе дөрес, принциплары нык иде.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ



САФИУЛЛИН ФӘНДӘС ШАКИР УЛЫ (17.08.1936 – 10.10.2021)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче, өченче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты (1999–2003), ике чакырылышта республика парламенты депутаты (1990–1999) Сафиуллин Фәндәс Шакир улы 10 октябрь көнне 86 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Фәндәс Сафиуллин 1936 елның 17 августында ТАССРның Азнакай районы Мәлбагыш авылында дөньяга килә. 1957 елда – Саратов танк училищесын, 1970 елда Белоруссия дәүләт университетын тәмамлый. 34 елдан артыграк вакыт дәвамында СССРның Кораллы Көчләрендә хезмәт итә, 1988 елда полковник дәрәҗәсендә отставкага чыга, шуннан соң ике ел дәвамында Казан ракета гаскәрләре югары хәрби команда-инженерлар училищесында өлкән укытучы, доцент булып эшли.

Фәндәс Шакир улы 1990 елда XII чакырылыш ТАССР Югары Советының халык депутаты итеп сайланды, Сугыш, хезмәт ветераннары, инвалидлар эшләре һәм шәфкатьлелек буенча даими комиссия рәисе булып торды. 1995 елда I чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, 1999 елда – III чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты итеп сайланды. 2000 елның гыйнварыннан Дәүләт Думасының Халыкара эшләр буенча комитетында хезмәт куйды.

Фәндәс Сафиуллин Татарстан Республикасының дәүләтчелеген һәм сәяси системасын үстерү өлкәсендә күп кенә закон проектларын эшләде, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында нәтиҗәле үзара мөнәсәбәтләр коруда актив катнашты.

Фәндәс Шакир улы татар халкының милли мәдәниятен, татар телен саклау һәм үстерү өчен эзлекле төстә көрәште, милли белем системасын булдыруга ярдәм итте, «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» республика законын эшләүдә катнашты.

Фәндәс Сафиуллин дәүләт хакимияте законнар чыгару органнарында эшләү дәверендә социаль-гуманитар өлкәне үстерүгә, парламентчылыкны һәм гражданлык җәмгыяте институтларын ныгытуга үзеннән лаеклы өлеш кертте.

Аның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы.

Фәндәс Сафиуллинга һәрвакыт бетмәс-төкәнмәс көч-энергия, иҗтимагый бурычка чиктән тыш тугрылык хисе һәм аерым бер эчке культура хас булды. Тормышта актив позициядә торуы, профессионализмы һәм гаделлеге аңа зур абруй-хөрмәт китерде.

Фәндәс Шакир улы Сафиуллинның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, А.В.Песошин, Ә.Ә.Сәфәров, М.Г.Әхмәтов, В.Г.Шәйхразыев, И.Р.Метшин, М.З.Шәйдуллин, Р.И.Вәлиев

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, уникенче чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты (1990–1995), беренче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (1995–1999), өченче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты (1999–2003)

Фәндәс Шакир улы САФИУЛЛИНның

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Күренекле җәмәгать эшлеклесе, татар милли хәрәкәтенең иң абруйлы шәхесләреннән берсе арабыздан мәңгегә китте. Фәндәс Шакир улы Татарстанның яңа тарихында үзеннән якты эз калдырды. Ул республиканың Дәүләт суверенитеты турында Декларация проектын эшләү буенча комиссия эшендә, 1990 нчы елларда Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара эшләр бүлешү турында Шартнамә җәһәтеннән сөйләшүләрдә, Татарстан Республикасы Конституциясен булдыруда актив катнашты. Фәндәс Шакир улы Татарстан парламентында милли мәдәниятне, татар телен саклау һәм үстерү буенча эзлекле төстә көрәште, милли белем системасын булдыру процессын хуплады. Профессионализмы һәм компетентлыгы, актив гражданлык позициясе Фәндәс Шакир улы Сафиуллинга коллегалары арасында һәм республиканың киң җәмәгатьчелегендә зур абруй-хөрмәт китерде.

Фәндәс Шакир улы Сафиуллинның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллективы, Татарстан Республикасы Мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институты элекке ректоры (1983–2004 елларда), профессор, Россия һәм Татарстан Республикасының атказанган укытучысы

ИСЛАМШИН Рәшит Әхәт улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Тәҗрибәле, максатка омтылышлы, югары дәрәҗәдә әхлаклы булуы Рәшит Әхәт улына хезмәттәшләре арасында зур абруй һәм хөрмәт китерде. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланачак, ә исеме Татарстан Республикасы тарихына кереп калачак.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты ветераны

ДӘҮЛИЕВ Илдус Әхмәтсафа улы

кинәт вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

СОҢГЫ СИКЕРҮ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Һәрхәлдә, төгәл нәтиҗәләр барлык тикшерү эшләре төгәлләнгәч билгеле булачак. Әлеге вакытта бу эш буенча җинаять эше ачылган. ДОСААФ, фаҗиганең сәбәпләрен ачыклаганчы, L-410 тибындагы самолетлар очуын туктатты. Шулай ук соңгы хәбәрләрдән аңлашылганча, Россиянең тикшерү комитеты башлыгы Александр Бастрыкин җинаять эшен тикшерүне ведомствоның үзәк аппаратына йөкләгән.

Очкыч һәлакәткә очраган урында булганнан соң Рөстәм Миңнеханов зыян күргән кешеләрнең хәлен белеште. Ул Чаллының Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсендә авырулар һәм табиблар белән аралашты.

Шул ук көнне Татарстан Премьер-министры җитәкчелегендә һәлак булучыларга һәм зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү максатыннан штаб барлыкка килде. Һәлак булганнарның гаиләләренә 1әр миллион сум күләмендә акча түләнәчәк. Сәламәтлегенә каты һәм уртача зыян килгән кешеләргә 400әр мең сум биреләчәк. Шулай ук республика мәрхүмнәрне җирләү белән бәйле мәшәкатьләрдә дә ярдәм итәргә әзер булуын белдерде.

«Минем өчен догада булыгыз...»

Һәлак булганнар арасында 29 яшьлек Илнар Гайфуллин да бар. «ВТ» хәбәрчесе аның танышы Алсу Насыйбуллина белән элемтәгә керде.

– Без икебез дә тумышыбыз белән Мөслим районыннан. Илнар белән бер мәктәптә укыдык. Ул миннән бер яшькә зуррак, туганымның якын дусты. Ул бик итагатьле, яхшы күңелле, ярдәмчел егет иде. Мәктәп елларында гел бергә булдык, якыннан аралашып яшәдек. Шат күңелле чын кеше иде. Актив, аралашучан егет булганга, аны районда белмәгән кеше юк, – дип искә алды Алсу.

Илнар узган ел гына сөйгәне белән никах укыткан булган. Быел исә туй иткәннәр.

– Алар бик озак очрашып йөрде. Бик матур пар иделәр. Хатыны да тыйнак, яхшы кыз, – диде ул.

Күптән түгел генә Илнарга 29 яшь тулган булган. Алсу әйтүенчә, дуслары аның парашют белән сикерү хыялы барлыгын белгәнгә, бүләккә сертификат биргән булганнар. Шуңа күрә кайбер туганнары хәтта аның фаҗига урынында булуын да белми калган. Якыннары Илнарның исән калуына соңгы минутка кадәр өметләнгән. Чөнки башта аның исеме хастаханәгә алып киткән кешеләр исемлегендә дә, моргка җибәрелгәннәр арасында да булмаган. Ләкин, кызганыч, өметләр акланмаган.

– Күпчелек туганнары матбугат чараларындагы хәбәрләр аша гына белгән. Хатыны һәлакәт турында ишеткәч, хастаханәгә барып көткән. Ләкин күпме генә көтсә дә, зыян күрүчеләр арасында Илнар булмаган. Без ахырга кадәр аның исән булуына өметләндек. Самолет ватыклары астында калгандыр, исәндер, дип уйладык, – дип сөйләде Алсу Насыйбуллина.

Илнарның социаль челтәрләрдәге соңгы посты үзенең туган көне уңаеннан куелган. Биредә ул бик тетрәндергеч сүзләр язган:

– Мине тәбрикләргә һәм нәрсәләрдер җибәрергә кирәкми. Бары тик минем өчен догада булыгыз. Аллаһы Тәгаләдән дөрес юлда булуымны, әти-әнием өчен лаеклы ул, хатыным өчен ныклы терәк, кыз туганым өчен ярдәмче һәм дусларым өчен тугры иптәш булуымны сорагыз…

Һәлак булганнар арасында Казан федераль университеты студенты Ксения Сәмигуллина да булган. Бу хакта уку йортының матбугат үзәге хәбәр итте. Кыз КФУның Идарә, икътисад һәм финанслар институтының икенче курсында укыган.

– Ксения бик шат, ачык, ярдәмчел, максатчан һәм ышанычлы кеше иде. Ул бик тырыш иде, чөнки сессияләрен уңышлы тапшыра иде, – диелгән уку йорты сайтында.

Соңгы мәгълүматлар буенча, фаҗигадә исән калган алты кешенең икесенең хәле уңайланган. Сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков аларны реанимациядән травматологиягә күчерүләрен хәбәр итте. Тагын бер авыруны Казанга – Республика клиник хастаханәсенә алып килгәннәр.

Мәрхүмнәрнең якыннарына – сабырлык, хастаханәдә булганнарга – саулык, һәлак булучыларга оҗмах түрләре насыйп булуын телибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Бу көннәрдә Россия һәм Татарстан җитәкчелеге төрле ил башлыкларыннан кайгы уртаклашу телеграммаларын ала. Кытай Халык Республикасы рәисе Си Цзиньпин Россия Президенты Владимир Путинга кайгы уртаклашу сүзләре юллаган. Рөстәм Миңнехановка Төрекмәнстан лидеры Гурбангулы Бердымөхәмәдовтан телеграмма килде.

– Минзәлә шәһәре янында L-410 самолеты һәлакәтенә бәйле рәвештә, тирән кайгыларны уртаклашам. Төрекмәнстан халкы һәм Хөкүмәте исеменнән, шулай ук шәхсән үз исемемнән югалтуларга һәм зыян күрүләргә бәйле бу авыр вакытта һәлак булганнарның барлык туганнарына һәм якыннарына сабырлык, шулай ук зыян күрүчеләргә тиз арада савыгу теләкләребезне җиткерүегезне сорыйм, – диелә телеграммада.

Ташказаннар сере

Чирмешән районының Кармыш авылы янәшәсендәге ташказаннарны карарга кайлардан гына килмиләр. Галимнәр арасында бу ташларны табигать һәйкәле диючеләр дә бар. Күрше-тирә авылларда яшәүчеләр, бу урыннан бала елаган тавышлар да ишетелгән, дип шомландыра. Башка беркайда да очрамаган ташлар «ВТ» хәбәрчесенә дә кызык тоелды.

Инстаграмда берәүнең ташказаннар янында төшкән фотосын куйгач, без дә битараф кала алмадык. Барыйк, күрик, дидек. Кармыш авылыннан ике чакрым ераклыкта гына булса да, әлеге урынны шактый эзләргә туры килде. Ни өчен дигәндә, бер язу да эленмәгән, сукмак та юк. Басу сөрүче тракторчы егет, тар гына сукмак күренер, дисә дә, үләннәр арасында калган юл тиз генә табылмады. Эзли торгач, таптык барыбер. Беренче карашка, ташлар ничектер җан ияләренә дә охшаган кебек тоела. Ә инде араларында үрмәли торгач, кузгалмаслык ташлар икәнен аңлыйсың. Монда килүчеләр һәрберсе нәрсәдер язып калдырырга тырышкан. Йөрәк рәсемнәре дә, гашыйкларның исемнәре дә бар монда. Бу хикмәтле ташларга карагач, ташказаннарда ашарга пешермәгәннәрме икән, дип тә уйлый башлыйсың. Үзенчәлекле ташларга сокланып йөрдек тә, тарихын белгән берәр кеше булмасмы дип, авыл мәктәбенә киттек.

Кармыш мәктәбенең укыту эшләре буенча директор урынбасары, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фирүзә Юнысова, ташказаннарның ничек барлыкка килүе турында төгәл мәгълүмат юк, диде. Шулай да халык телендә йөргән риваятьләр бар икән. Нариман Кәримов «Кармышым» дигән китабында да язган бу хакта.

– Без дә анда кечкенә чакта бара идек. Галимнәр дә килгәләде, хәзер географлар өчен дә кызыклы урынга әйләнде ул. Әмма ничек барлыкка килүен берәү дә белми, – ди ул.

Фирүзә Юнысова әйтүенчә, халык телендә ташказаннар җир астында булган, язгы ташулар агып, аны шомартып, түгәрәк формага китергән дигән фаразлар бар. Монысы – беренчесе. Икенчесе – колхозлашу чорында анда төрле районнардан колхозга кермәгән кулакларны сөргәннәр. «Җилле, яшәргә җайсыз җирләр бу. Анда аларның эчәргә сулары да булмаган. Җирне казып, шунда яшәү урыны булдырганнар. Яңгыр суларын җыеп эчкәннәр. Соңрак аларны Чита, Магнитогорск якларына җибәргәннәр, – ди ул. – Казан кебек җире дә бар. Шунда ашарга пешергәннәр, керләрен юганнар дигән ышанулар да бар. Бик туры килеп тә бетми кебек. Казаннар әйләндереп капланган кебек. Язулары да бар. Кем төшә, шунда нәрсә булса да язып калдыра. Борынгы латин, гарәп язулары юк. Астан яңа ташлар да чыга. Мондый урын тагын кайдадыр булырга мөмкин әле».

2016 елда Фирүзә Юнысова укучылары белән авылның тарихи урыннары дигән проект эшләгән, фильм да төшергәннәр. Мәктәпкә семинарга килгән укытучыларга да шуны күрсәтәләр икән. «Кызык, дип китәләр. Район географлары да ташказаннарны карарга килде. Түбән Камадан балалар белән эшләүче киностудия дә фильм әзерләп, социаль челтәрләргә куйган иде. Бу урын белән кызыксынучылар тагын да артыр әле», – ди ул.

Яшәүче авылыннан бу җирләр – кул сузымында гына. Әлеге авылда яшәүче Илшат Харисов әйтүенчә, анда Лишун дигән авыл булган. Кирлемар тавындагы ташказаннар тирәсенә муллаларны сөргәннәр. Лишуннар киткәч, күп еллар дәвамында ул урында бала елаган тавышлар ишетелгән.

– Кечкенә вакытта Пионер туган көнендә «Лишун» чокырына бара идек. Хәзер туйлар вакытында да киләләр. Лишун авылы кешеләре безнең авылга хәер сорашырга төшкән. Авылдашларыбыз Коръән мәҗлесләрендә Лишун авылы әрвахларына да дога кыла. Яңгыр яумаганда, шунда барып намаз укыйлар. Серле урын ул, – ди Илшат Харисов.

Альберт БОРҺАНОВ, тарихчы-археолог:
– Чирмешән районы буенча экспедиция уздырган идем. Кармыш авылында яшәгәндә, ул урынны әйләнеп кайткан идек. Бу – табигать һәйкәле. Җир асты сулары агып, ташларны шомарткан. Тарихта андый нәрсәләр күп. Әмма Татарстан өчен бу – сирәк очрый торган уникаль ташлар. Кешеләр эшләгәндер дип уйламыйм. Бик кызык нәрсә бу. Моны туризм маршрутына да кертергә булыр иде.

Сәрия МИФТАХОВА



Илдар Мөхәммәтҗанов

ӨЧ КИЯҮ БЕЛӘН ТОРМЫШ

Тинчурин театры яңа театраль сезонында беренче премьерасын тәкъдим итте. Театр репертуарын Салават Юзеев пьесасы буенча режиссер Регина Саттарова куйган комедия белән баетмакчы. Баер өчен дипме шунда, кияү урларга ниятләгәннәр.

tinchurinteatr.ru

Спектакльнең исеме үк Тинчурин театры репертуарындагы «кияүләр» алтын коллекциясен (Рәшит Заһидуллинның «Кияүләр» һәм «Назлы кияү» комедияләре турында сүз бара) «тулыландыра». Кайчандыр Рәшит Заһидуллинның укучысы булган Регина Саттарова «Кияү урлау» әсәренә алынган.

Соңгы һәм изге әманәт тарихы

Сценарийны гади һәм традицион дип әйтергә мөмкин: кайчандыр ике дус – Азват белән Садрый туганлашырга уйлыйлар. «Әгәр беребездә кыз, ә икенчебездә малай туса – өйләндерәбез!» – дип, ант әйтешәләр. Ләкин икесенең дә малай туа. Бу өлешен без күрмибез – мәгълүмати буклетта язылганнарны гына сөйлим. Сәхнәдәге күренешләр Азват бабайның үләренә өч көн калган мизгелдән башлана. Үзе генә калганда, бар да тәртиптә бабайның. Ә янына кеше, бигрәк тә килене килсә, хәтере борчый башлый.

Менә шул карт дустына биргән күптәнге антын искә төшерә. Искә төшерә дә бу йола балаларыннан оныкларына күчәргә тиеш дигән нәтиҗәгә килә. Әманәт – изге нәрсә! Әмирхан Еникиның Акъәбисе искә төште бу урында. Ата-ананың хакын хаклау – сак кына булса да, Салават Юзеев бу темага да кагылган. Азват бабай балаларын, мин антымны үти алмасам, нәселгә бәхетсезлек яный, дип куркыта. Башта бик карышсалар да, улы белән килене аңларга тырышалар үзен.

Азват бабай ролен Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Зөфәр Харисов башкара. Гомумән, соңгы арада куелган пьесаларда бабай образын Зөфәр абыйга туры китереп «тудыралар» кебек тоела башлады. Аксакаллар һәрвакыт кирәк ул, әмма без классик әсәрләрдәге сыйфатлардан китә алмыйбыз сыман...

«Татарча боевик» төшерү тарихы

Татар җырламыйча яши алмый. Кайгы килсә дә, шатлыктан башын күккә бәргәндә дә. «Кияү урлау»да күп тапкыр яңгырады бу фикер. Әлеге комедиянең эскизы Милли драматургия һәм театр журналистикасы буенча «Алкыш» театраль лаборатория-семинары кысасында күрсәтелде. Ул чакта ук композитор Гөлнара Тимербулатова пьесаның музыкаль өлеше өчен җаваплы итеп билгеләнгән иде. Гадәттә, спектакльдә яңгыраган җырлар озак кына баш миенә тынгылык бирми. Бу юлы алай булмады.

Җырлы-биюле тагын бер күренеш ике дус – Равил (Зөлфәт Закиров) белән Ривалның (Салават Хәбибуллин) татар кинематографиясен «күтәргән» чагында булды. Имеш, шәп фильм төшереп, «Оскар» алачаклар. Ләкин бу бүләк күбрәк Равилгә кирәк, шуңа ул күбрәк сикерә дә. Дусты Ривал, килделе-киттеле һәр идеяне хуплап, салам арасында казынып ятуын гына белә. Берзаман икәүләшеп уртак бер фикергә киләләр: татарга боевик кирәк! Сценарий исә болайрак: мылтык тоткан һәм кара битлек кигән кешеләр банкка үтеп керәләр һәм акча урларга тотыналар. Нәрсәсе бар инде моның, диярсез. Ләкин бу – милли боевик, шуңа күрә ахырдан, кем булуына карамастан, бөтен кеше бии башлый. Татарча, әлбәттә. Менә ул – безнең йөзебез! Үзе дә кинорежиссер булган Салават Юзеевтан яхшы гына ирония монысы. Ләкин бу сюжет линиясе шуның белән өзелә, тема дәвам ителми. Бәлки, дәвам итәргә кирәк булгандыр?

Урланган кияүнең гашыйк булу тарихы

Комедия традицион килеп чыккан дип әйткән идем инде. Башына капчык кидерелгән, гәүдәсен бәйләнгән килеш «карак» атка утыртып, күрше авылга алып килгән «кияү» егет «кәләш»енә гашыйк булмаса, мондый фикергә килмәс идем дә, мөгаен. Көлке вакыйга мәхәббәт тарихы тудыра. Ниндидер зур хисләр, илаһи мәхәббәт микән соң инде ул – анысы әйтелми. Ләкин халык башта көлә, аннан соклана. Кассага уңай тәэсир итәр кебек бу әсәр. Галим Әлфәт Закирҗанов та шул фикердә:

– «Кияү урлау» – уен-көлке, халыкчан юморга нигезләнгән спектакль. Ул – кеше психологиясен, аның төрле халәтен ачуга юнәлдерелгән һәм шул ук вакытта тамашачы уенда ниндидер идея, уй-фикер калдырмый торган әсәр. Әлеге спектакльнең эчтәлеген, рухын күпмедер дәрәҗәдә озак еллар Камал театрында барган «Казан егетләре» белән чагыштырырга мөмкин. Икесе дә – шактый беркатлы әсәрләр. Икенче яктан карасак, безнең тамашачы нәкъ менә шундый уен-көлкеле тамашаларга яратып йөри. Тинчурин театры тәкъдим иткән әлеге спектакльне дә халык яратыр кебек. Халык кына түгел, әлеге әсәрне «Алкыш» театраль лаборатория-семинарына килгән театр тәнкыйтьчеләре куелыш ягын да, актерларның уенын да югары бәяләде. Шәхсән мин бу спектакльне икенче тапкыр барып карамас идем, – диде ул.

Күптән түгел генә Тинчурин театрында баш режиссер вазыйфасына билгеләнгән Туфан Имаметдинов та, әсәрнең кимчелекле яклары юк түгел, ди:

– «Кияү урлау» – лабораториядән чыккан эскиз. Әлеге әсәрне репертуарга кертү турында карар кабул ителгәндә дә, пьесаны сәхнәгә чыгарырга әзерләнгән чакта да мин баш режиссер вазыйфасында түгел идем. Шуңа күрә ни өчен нәкъ менә бу әсәр сайлануы турында берни дә әйтә алмыйм. Мондый рухтагы спектакльләр бездә бар югыйсә. Татарда туйдан башка тема юк диярсең. Драматургия ягыннан да кимчелекләр күренә. Әмма әсәрдәге ситуация кызык, тирәнрәк ачылган булса, тагын да яхшырак булыр иде. Драматургия өлешендә булган кимчелекләрне шәп куелыш белән дә «капларга» була үзе. Ләкин режиссер һәм әсәр алдан сайлангач, мин каршы килмәдем. Кешене ышандырганнар бит инде, безнең яктан дөрес булмас иде ул. Аннан соң, тамашачы өчен дә кызыклы әсәр бу, яратып йөрерләр дип уйлыйм.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЛЮЦИЯ СӘЛӘХИЕВА:

«УТ БЕТМӘСЕН ДИП ТЕЛӘП ТОРАМ»

Шөгыль

Казанда яшәүче Люция СӘЛӘХИЕВА камыр ризыклары пешерә. Югары белем алып, дипломлы булгач та, укыган һөнәренә күңеле ятмый. Кечкенәдән әнисеннән өйрәнгән камыр ашлары пешерү күңеленә күбрәк хуш килә аның. Шуңа пешекче булып эшкә урнаша.

– Мине әни кечкенәдән эшкә өйрәтеп үстерде. Камыр ризыкларын бик яратып пешерә идем. Шуңа да ресторанга эшкә урнашу авыр булмады. Кияүгә чыгып, декретка киткәч, заказларны өйгә бирә башладылар, – дип сөйли Люция. – Баштарак эшем дә, керем дә әллә ни күп булмады. Әмма бер-берсеннән ишетеп, заказ бирүчеләр арта башлады. Икенче баламны тапкач, үзмәшгуль булып теркәлдем. Хәзер инде көн саен 4–5 пирог пешерәм. Тәмле, диләр. Бисмилла әйтеп пешергәнгә шулай ул. Бәлешкә дә заказ бирүчеләр күп.

Бәлеш дигәннән, Люция бервакыт чактан гына оятлы булмый кала. Бер көнгә дүрт бәлешкә заказ алган була икән. Дәфтәрен ачып караса, бәлешләр бер үк сәгатькә кирәк. Өйләрендәге мичкә ике генә бәлеш сыя. Нишләргә? Ярый күрше кызы ярдәмгә килә.

– Ике бәлешне аларда пешердек. Ерактарак яшәгән кешегә бәлешләрне үзем илтеп бирдем, килеп алучыларга күршем тапшырды. Шул көнне бик борчылган идем. Башка уңайсыз хәлдә калганым юк. Ризык тәмсез булыр дип тә кайгырмыйм хәзер. Бәлешне дә тишелер дип борчылмыйм. Аның өчен камырны озак итеп басарга гына кирәк, – ди ул.

Люциянең миче утка тоташтырылган. Шуңа да бар теләге – ут кына бетмәсен! Әлегә утсыз калганы булмаган. Әмма заказлары күп булганда клиентларын башка пешекчеләргә җибәрә икән.

– Буш вакытымда ярымфабрикатлар да ясап куйгалыйм. Аларны кеше күп сорый. Булса, хәзер алып бетерәләр. Кеше, акчасын түләп, сатып кына алырга өйрәнде. Ә миңа исә пешерү тынычлык, рәхәтлек бирә. Акчасы да комачау итми. Белгән эшне эшлисе генә килеп тора аны, – ди Люция.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЛЮЦИЯДӘН «КЫРМЫСКА ОЯСЫ» РЕЦЕПТЫ

Камыр өчен 200 грамм атланмай, 0,5 стакан шикәр комы, 4 стакан он, 0,5 стакан каймак, сода белән серкә кирәк. Атланмайны эретергә дә шуңа шикәр комы, каймак, сода кушасың. Әкрен генә болгата-болгата камыр басасың. Камыр каты булырга тиеш. Аны иттарткычтан чыгарасың. Шул камырны 200 градуслы мичтә 20 минут пешерәсең. **Крем өчен** 1 банка куертылган сөт белән 50 грамм атланмай кирәк була. Аларны 40 минут кайнатып алырга кирәк. Пешкән камырны крем белән бутап, тау шикелле өеп, өстенә шоколад валчыгы сибәргә.

Люция Сәләхиеваның шәхси архивыннан

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7405 данә
Гомуми тираж – 17243 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 348

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+